ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 73 от «15» 03 2019 г.

Мамадыш муниципаль районында
Татарстан Республикасы халыклары телләре турындагы
Татарстан Республикасы Законын гамәлгә
ашыру комиссиясе турында

“Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, “2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү” дәүләт программасы кысаларында һәм Мамадыш муниципаль районында телләр турында Татарстан Республикасы Законнарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районында Татарстан Республикасы халыклары телләре турындагы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру комиссиясен төзергә. (алга таба - Комиссия).
2. Татарстан Республикасы телләр турындагы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча төзелгән Мамадыш муниципаль районы комиссиясе турында Нигезләмәне 1нче Кушымта нигезендә расларга .
3. Татарстан Республикасы телләр турындагы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча төзелгән Мамадыш муниципаль районы комиссиясе составын 2нче Кушымта нигезендә расларга .
4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов

Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының
15.03 2019 ел, 73 нче санлы
карарына 1 № лы кушымта

**Татарстан Республикасы телләре турында Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру буенча Мамадыш муниципаль районы комиссиясе турында**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру комиссиясе Мамадыш муниципаль районында (алга таба - Комиссия) Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Мамадыш муниципаль районында яшәүче башка халыкларның телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатларында (алга таба - телләр өлкәсендә дәүләт сәясәте), Мамадыш муниципаль районы гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Мамадыш муниципаль районында яшәүче халыкларның башка телләреннән файдалануга хокукларын тәэмин итү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, җәмәгать һәм башка оешмаларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

1.2. Комиссия үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, гамәлдәге федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Законнары, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы һәм әлеге Нигезләмәгә таянып гамәлгә ашыра.

## 2. Бурычлар

2.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга, гражданнарның Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Мамадыш муниципаль районында яшәүче халыкларның башка телләрен файдалануга хокукларын тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар арасында үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру.

2.2. Телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтенә кагылышлы программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыруда ярдәм итү, күрсәтелгән программалар һәм проектларның нәтиҗәлелеген анализлау, кирәк булганда аларны үзгәртү турында тәкъдимнәр эшләү.

2.3. Мамадыш муниципаль районында телләр турындагы законнарның үтәлешенә мониторинг үткәрү.

2.4. Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча структур бүлекчәләргә, фәнни оешмаларга, мәгариф оешмаларына методик һәм консультацион ярдәм күрсәтү.

## 3. Функцияләре

3.1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына, дәүләт хакимияте органнарына Мамадыш муниципаль районында телләр турындагы законнарны гамәлгә ашыруны камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертү.

3.2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре эшчәнлеген телләр турындагы законнарны гамәлгә ашыру өлкәсендә контрольдә тоту һәм эшләү.

3.3. Утырышларда Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты структур бүлекчәләре җитәкчеләре, вәкилләре, хакимият, иҗтимагый оешмалар, фәнни җәмәгатьчелек вәкилләренең Мамадыш муниципаль районында телләр турындагы законнарны гамәлгә ашыру турындагы докладларын тыңлау.

3.4. Мамадыш муниципаль районы территориясендә эшләп килүче дәүләт һәм муниципаль органнар, иҗтимагый берләшмәләр, фәнни җәмәгатьчелек вәкилләре белән телләр турындагы законнарны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек.

3.5. Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә, Мамадыш муниципаль районы территориясендә урнашкан теләсә нинди формадагы оешмаларга Мамадыш муниципаль районында дәүләт телләрен паритеттан файдалану өлкәсендә хокук бозуларны бетерү һәм булдырмау максатларында карарлар кабул итү өчен мәгълүмат бирү.

## 4. Хокулары

4.1. Билгеләнгән тәртиптә Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты структур бүлекчәләреннән, иҗтимагый берләшмәләрдән, мәдәният һәм сәнгать оешмаларыннан, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалардан, шул исәптән телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлек башкаручы коммерцияле булмаган оешмалардан, шулай ук аларның вазыйфаи затларыннан кирәкле материалларны соратып алырга.

4.2. Кирәк булганда, билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре белгечләрен, Комиссия компетенциясенә керә торган карарлар һәм башка материалларны әзерләүдә катнашу өчен хуҗалык итүче субъектларны җәлеп итәргә.

4.3. Үз вәкилләрен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар, шул исәптән телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар тарафыннан үткәрелә торган киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен җибәрергә.

## 5. Эшне оештыру

5.1. Муниципаль комиссия рәис, аның ике урынбасары, сәркатип һәм әгъза составында төзелә, шулай ук комиссия составына кермәгән галимнәр, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре, педагоглар, Татарстан Республикасы һәм Мамадыш муниципаль районы дәүләт һәм муниципаль хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар, даими һәм вакытлы комиссияләр (эшче төркемнәр) вәкилләре арасыннан төзелә. Комиссия составы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

5.2. Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүче Рәис Комиссия эшчәнлеген тәэмин итүче карарлар кабул итә, Комиссия әгъзаларының эшен координацияли, чираттагы утырышта каралырга тиешле мәсьәләләр даирәсен билгели, Комиссия утырышын билгели, шул исәптән Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекчәләре , ведомство карамагындагы оешмалар һәм башка хакимият һәм идарә органнары җитәкчеләре һәм вәкилләре катнашында да билгели. Комиссия эше нәтиҗәләре буенча үз вәкаләтләре кысаларында карарлар кабул итә. Вакытлыча комиссия рәисе булмаган очракта, аның вазыйфаларын рәис урынбасарлары башкара.

5.3. Комиссия секретаре утырыш беркетмәләрен алып бара, комиссия тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлеше турында мәгълүмат әзерли, комиссия утырышларына әзерлекне оештыра, төрле ведомстволардан алынган мәгълүматны җыю һәм гомумиләштерүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыра, билгеләнгән тәртиптә башкарма хакимият органнарыннан һәм башка оешмалардан комиссия компетенциясендә булган мәсьәләләр буенча мәгълүматны соратып ала.

5.4. Комиссия утырышлары ярты елга бер тапкырдан да ким булмаска тиеш. Кирәк булган очракта комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы санала.

5.5. Комиссия карарлары комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышларның тигезлеге булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

5.6. Комиссия карарлары беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә һәм комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан имзалана.

5.7. Комиссия карарлары үтәлешен комиссия рәисе урынбасары контрольдә тота.